| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2023 № 319

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 143 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1415 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 143 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.3 бүлегендәге 3.3.2 пунктының 3.3.2.1 пунктчасындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Элетрон формада гаризаны формалаштырганда, мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасы кырларын тутырганнан соң, форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы гаризаның ялгыш тутырылган кыры ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмати хат аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.А. Мусаев

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00A3E71B096428C7D14E82404E46486D21

Владелец: Мусаев Руслан Амирах Оглы

Действителен с 13.04.2022 до 07.07.2023



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН